**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ**
**ЛЬЯШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТӘТЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЛЬЯШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

422375 с. Льяшево, ул. Пролетарская, 22А

422375 Льяш авылы, Пролетар урамы, 22А

тел., факс (84373) 55-8-26, e-mail: Lsv.tet@tatar.ru
ОГРН 1021606556971, ИНН/КПП 1638001624/163801001

# РЕШЕНИЕ

**05 ноября 2019 года** **№ 49-1**

## О назначении местного референдума

2002 елның 12 июнедәге «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 маддәсе, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 маддәләре, 2004 елның 24 мартындагы «Җирле референдум турында " 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы «Льяшево авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Льяшево авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Льяшево авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум үткәрүне 2019 елның 22 декабренә билгеләргә.

2. Җирле референдум үткәрү вакытын: 07:00 - 20:00; үткәрү урынын: Татарстан Республикасы Тәтеш районы Льяшево авылы, Пролетарская ур., 22а й.; Татарстан Республикасы Тәтеш районы, Олы Бисәр авылы, Мәктәп ур. 25й. билгеләргә

3. Җирле референдумга сорауны түбәндәгечә формалаштырырга (әйе/юк):

3.1«Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районыны Льяшево авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларына хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 2020 елда 700 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм аннан алынган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлдерүгә сез риза буласызмы:

- Льяшево авылы, Олы Бисәр авылы, Ямбакты авылы эчендәге юлларны төзекләндерү;
- Льяшево авылына, Олы Бисәр авылына, Ямбакты авылына чүп контейнерлары сатып алу;;
- Льяшево авылына, Олы Бисәр авылына, Ямбакты авылына урамнарны яктырту өчен лампалар һәм махсус җиһазлар сатып алу;
- Ямбакты авылында һәлак булган сугышчыларга обелиск төзү һәм төзекләндерү
- Льяшево авылында чишмәне төзекләндерү;

- Льяшево авылында карт агачларны кисү?».

3.2. «Сез 2018-2019 еллардагы гражданнарның 49 928,40 сум күләмендәге үзара салым акчаларын яңадан бүләргә «-Олы Бисәр авылы зираты территориясен койма белән әйләндереп алу»дан «-Олы Бисәр авылында һәлак булган сугышчыларга куелган обелиск территориясен койма белән әйләндереп алу»га ризамы;

- Олы Бисәр авылына чишмә өчен бура сатып алу;

- Олы Бисәр авылы эчендәге юлларны төзекләндерү?».

4. Җирле референдум уздыруга бәйле чыгымнарны Льяшево авыл җирлеге бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тәтеш районы Льяшево авылы, Пролетарская ур., 22а й.; Олы Бисәр авылы, Заовражная ур., 33й.; Ямбакты авылы, Октябрнең 60 еллыгы ур., 24а й. адреслары буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълъмат рәсми порталында урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы**
**Льяшево авыл җирлеге башлыгы** **И.А. Тихонова**